СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.12.2023 г. Заинск № 308

**Зәй муниципаль районы Советының 2021 елның 7 октябрендәге 170 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру нигезләмәсен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроле турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы законга, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 10 мартындагы 336 номерлы карарының 3 пунктындагы а пунктчасы белән, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру нигезләмәсен раслау турында» 2021 елның 7 октябрендәге 170 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру Нигезләмәсенә» (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2021 елның 27 декабрендәге 195 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) кушымта буенча яңа редакциядәге 3 нче кушымтаны бәян итеп үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында www.zainsk.tatar.ru. урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Советының Экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, ТКХ һәм транспорт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәис** **Р.Г. Кәримов**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы Советы карарына
кушымта
28.12. 2023 елдан № 308

Татарстан Республикасы Зәй
муниципаль районы территориясендә
муниципаль торак контролен гамәлгә
ашыру нигезләмәсенә
3 нче кушымта

Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда планнан тыш тикшерүләр үткәрү кирәклеген билгеләү өчен кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

1. Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматлары буенча, контрольдә тотылган зат идарәсендә булган күп фатирлы йортта гомуми милектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча эш алып бару өчен атнага биштән артык бригада чакыру очрагы.

2. Россия Федерациясе Торак Кодексының 165 статьясының 5 өлеше нигезендә билгеләнгән тәртипкә, формаларга, срокларга һәм вакытлычалыкка ярашлы рәвештә торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиешле мәгълүматның өч һәм аннан да күбрәк ай дәвамында актуальләшмәве.

3. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларында күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан артык арттыру турында белешмәләрне ачыклау.